**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**16 октябрь, 2023 ел** **№ 335**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча 2023 елның 14 сентябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен, 2023 елның 14.09. – муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына, аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш.Шакиров

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектына материаллар белән территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми (https://fgistp.economy.gov.ru) УИН 92622458020203042023О9131 буенча танышырга мөмкин.